| ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ<br>АКСАРИНСКОГО СЕЛЬСКОГО<br>ПОСЕЛЕНИЯ ЗАИНСКОГО<br>МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА<br>РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | | ТАТАРСТАН<br>РЕСПУБЛИКАСЫ ЗӘЙ<br>МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ<br>АКСАР АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ<br>БАШКАРМА КОМИТЕТЫ |
|---|---|---|

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

**«24» марта 2025г** **№6**

**Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районының Аксар авыл җирлеге территориясендә йорт хайваннарын йөртү урыннарын билгеләү турында**

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 06 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль Закон, «хайваннар белән җаваплы мөгамәлә турында һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү хакында» 2018 елның 27 декабрендәге 489-ФЗ номерлы Федераль закон, Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районы Аксар авыл җирлеге Советының 25.12.2018 елгы 136 номерлы карары нигезендә «Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районының Аксар авыл җирлеге территориясен төзекләндерү кагыйдәләрен раслау турында», Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районының Аксар авыл җирлеге Уставына таянып, Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районының Аксар авыл җирлеге башкарма комитеты

КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районының Аксар авыл җирлеге территориясендә йорт хайваннарын йөртү өчен, күрү сәләте буенча инвалидны озата йөрүче юл күрсәтүче эттән тыш, түбәндәге урыннарны билгеләргә:

- файдаланудагы яисә хуҗа милкендәге җир кишәрлекләре;
- халык күп җыелмый торган авыл җирлеге территориясендә бушлыклар, торак сектор һәм җәмәгать урыннары артындагы урыннар, борындыкларда һәм тезгеннәрдә аларның хуҗалары күзәтүе астында:
  - Аксар авылының көньяк-көнчыгыш өлешендә Вахитов урамыннан 60 метр ераклыкта;
  - Аксар авылынын төньяк өлешендә Ленин урамыннан 60 метр ераклыкта;
  - Иске Тәкмәк авылының төньяк өлешендә Ленин урамыннан 60 метр ераклыкта;
  - Өченче Бөгелде авылының көньяк-көнбатыш өлешендә Луговая урамыннан 60 метр ераклыкта;

- Перцовка авылының көньяк өлешендә Дачная урамындагы 32 нче һәм 4 нче йортлар арасындагы тыкрыктан 60 метр ераклыкта;

- Икенче Бөгелде авылының көньяк өлешендә Пушкин урамындагы 7 нче һәм 8 нче йортлар арасындагы тыкрыктан 60 метр ераклыкта;

- Бүре-Сарай авылының төньяк-көнбатыш өлешендә Речная урамыннан 60 метр ераклыкта;

- Яңа Тәкмәк авылының төньяк өлешендә Шоссейная урамыннан 60 метр ераклыкта.

Әлеге пунктның тәэсире эт йөртүчеләргә кагылмый.

2. Әлеге карар рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

3. Әлеге карарны Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталында бастырып чыгарырга (PRAVO.TATARSTAN.RU), җирлекнең торак пунктлары территориясендәге махсус мәгълүмат стендларында һәм Зәй муниципаль районының рәсми сайтында «авыл җирлекләре»бүлегендә урнаштырырга.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үземдә калдырам.

Башкарма комитет
җитәкчесе — Ю.И.Гыйлманов